Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«24» ноябрь 2021 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 24 ноябрендә узган: «Сез 2022 елда Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлыгы булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2000,00 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Урта Чаллы авылын су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр үткәрү;
Урта Чаллы торак пункты чикләрендәге юлларны ремонтлау мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 39 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 81 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 62 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 19 катнашучысы тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Сез 2022 елда Иске Чаллы авыл җирлеге Урта Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлыгы булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 2000,00 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне башкару буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Урта Чаллы авылын су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр үткәрү;

Урта Чаллы торак пункты чикләрендәге юлларны ремонтлау мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Чаллы авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: И.Н. Захаров

Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Захаров